ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлегенең Мияш торак пунктында
2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

“27” ноябрь 2021ел **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Мияш торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге Мияш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1-2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

Мияш торак пунктында су башнясы территориясен тозеклендеру (скважина коймаларын урнаштыру өчен материаллар сатып алу, килешү буенча эшләргә түләү).

3. Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://menselinsk.tatarstan.ru), кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы З. С.Гәрәева
(имза) (имзаны киңәйтү)